**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

**2016 елның 30 сентябре №36**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү һәм уздыру турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районыКече Салтык авыл җирлегенең 15 статьясы, «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече кама авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 28 сентябрендәге 165 номерлы карары, «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 2014 елның 30 мартындагы 1635 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2016 елның 20 ноябренә җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«2017 елда үзара салым акчаларын Кече Салтык авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән тавыш бирү хокукына ия һәр гражданнан 300 сум күләмендә кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

***җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**

- Кече Салтык авылында Октябрь ур., Комсомол ур. юлларны ремонтлау;
-Кече Мәрәтхуҗа авылында Декабристлар, Кооператив урамындагы юлларны ремонтлау;
- Яшелчә авылындагы Идел урамындагы юлларны ремонтлау;

- торак пунктларда юлларны кышын карап тоту.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманче ур., 9, Мәдәният йорты бинасы;
- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов ур., 9 йорт, авыл китапханәсе мәдәният йорты бинасына;
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Яшельч авылы, Идел ур., 4а, авыл клубы бинасы, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кече Салтык авыл җирлеге башлыгы А.Г. Җиһаншинга йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге башлыгы , Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советы рәисе ;**
**А.Г. Җиһаншин**